**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының "Кодаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлек составына керүче Кодаш авылы**

**торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**2025 елның 24 октябре № 2**

**Кодаш авылы, авыл мәдәният йорты**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Кодаш авыл җирлеге» Кодаш авылы торак пунктында гражданнар җыены

карар кылды:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кодаш авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип танылган гражданнардан, өч һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган баласы булган күпбалалы гаиләләрдән, срочный хезмәттәге хәрби хезмәткәрләрне, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500,00 сум күләмендә гражданнарга үзара салым кертергә.

2.Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (Кодаш елгасы үзәнен үсемлекләрдән чистарту, чүп-чарны чыгару, агачларны кисү);

- Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (материал сатып алу һәм Кодаш авылы торак пунктына кергәндә стеланы реконструкцияләү (ремонтлау) эшләрен башкару);

- Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Кодаш авылы урамнарын чистарту, куакларны бетерү, агачларны йоклату һәм чыгару).

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**

**«Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы**

**Г. Ә. Хәйсарова**